**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«31» октябрь 2024 ел Яр Чаллы № ________

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) гамәлгә ашыру планлаштырылган инвестицион проектларны «бер тәрәзә» принцибы буенча алып бару регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында инвестицион эшчәнлек турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, инвестицион активлыкны арттыру һәм инвестицион эшчәнлекне үстерү өчен уңай шартлар тудыру, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында гамәлгә ашырыла торган (гамәлгә ашыру планлаштырылган) инвестицион проектлар буенча мәгълүматларны исәпкә алуны системага салу максатында,

## КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан РеспубликасыТукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) гамәлгә ашыру планлаштырылган инвестицион проектларны «бер тәрәзә» принцибы буенча алып бару регламентын расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад һәм эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү буенча беренче урынбасары Галимова Гөлнара Әзгать кызын инвестиция буенча вәкаләтле (алга таба - инвестиция буенча вәкаләтле) дип билгеләргә, аның төп бурычkfhsы булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә инвестиция проектларын гамәлдә ашыруга һәм яңа инвесторлар җәлеп итүдә ярдәм күрсәтү тора.
3. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) гамәлгә ашыру планлаштырылган инвестицион проектларны «бер тәрәзә» принцибы буенча алып бару регламентын раслау турында» 2024 елның 15 январендәге 02 номерлы карар үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинга йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.И. Закиров

Муниципаль район Башлыгының 2024 елның «____»____________ ___ номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) гамәлгә ашыру планлаштырылган инвестицион проектларны «бер тәрәзә» принцибы буенча алып бару регламентын раслау турында**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) гамәлгә ашыру планлаштырылган инвестицион проектларны «бер тәрәзә» принцибы буенча алып бару регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә һәм аларга булышлык күрсәтүгә һәм уңай инвестицион климат тәэмин итүгә юнәлтелгән.

1.2. Регламент Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә уңай инвестицион климат булдыру, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының (алга таба – Башкарма комитет) инвесторлар белән үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатында эшләнде.

1.3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла һәм (яки) гамәлгә ашыру планлаштырылган инвестицион проектлар реестрына кертү өчен карау этабында инвестицион проектлар инициаторына мәгълүмати консультация һәм оештыру ярдәме күрсәтүче структур бүлекчә булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге (алга таба – Бүлек) тора.

1.4. Әлеге Регламент Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәдәге бюджетлары хисабына финанслана торган инвестиция проектларына кагылмый.

1.5. Әлеге Регламент максатларында түбәндәге терминнар кулланыла: инвестицияләр – акчалата средстволар, кыйммәтле кәгазьләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары, табыш алу һәм (яки) башка файдалы нәтиҗәгә ирешү максатында эшмәкәрлек һәм (яки) башка эшчәнлек объектларына кертелә торган акча бәясе булган башка хокуклар;

инвестицион эшчәнлек – табыш алу һәм (яки) башка файдалы нәтиҗәгә ирешү максатында инвестицияләр кертү һәм практик гамәлләр башкару;

инвестицион мәйданчык – Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә инвестицион проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге;

инвестицион проект – капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруның икътисади максатка ярашлылыгын, күләмен һәм срокларын нигезләү, шул исәптән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә эшләнгән кирәкле проект документациясе, шулай ук инвестицияләрне гамәлгә ашыру буенча практик

гамәлләрне тасвирлау (бизнес-план);

инвестор – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үзенең, заемга алынган яки җәлеп ителгән средстволарны кертүне гамәлгә ашыручы һәм югарыда күрсәтелгән средстволарны максатчан куллануны тәэмин итүче инвестицион эшчәнлек субъекты;

инвестицион проект инициаторы – Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга инвестицион проект тәкъдим итүче физик яки юридик зат;

капиталь кертемнәр – төп капиталга инвестицияләр (төп средстволар), шул исәптән яңа төзелеш, реконструкция һәм гамәлдәге предприятиеләрне техник яктан яңадан кораллandыру, машиналар, җиһазлар, инструментлар, инвентарь сатып алу, проект-эзләнү эшләре һәм башка чыгымнар;

куратор – инвестицион проектны алып баруны тәэмин итүче Башкарма комитет хезмәткәре;

мөрәҗәгать – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына инвестор тарафыннан инвестицион проектны гамәлгә ашыру, инвестицион проектны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеген сайлап алуда һәм җир кишәрлеген инфраструктура белән тәэмин итүдә инвесторга ярдәм күрсәтү, инвесторның җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, инвестицион проектны гамәлгә ашыручы яки гамәлгә ашыруны күздә тотучы инвесторның башка сорауларын үз эченә алган гариза;

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла һәм (яки) гамәлгә ашыру планлаштырылган инвестицион проектларны алып бару буенча чаралар план - графигы (алга таба – план - график) – инвестицион проектны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән чараларны үтәү графигы;

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының өстенлекле инвестицион проекты – Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезендә гамәлгә ашырыла торган инвестицион проект;

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестицион проектлар реестры (алга таба – Реестр) – Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) гамәлгә ашыруга тәкъдим ителгән, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге алып бара торган инвестицион проектлар исемлеге;

инвестицион проектның резюмесы – проект инициаторы тарафыннан инвестицион проект турында билгеләнгән форма буенча рус һәм инглиз телләрендә тәкъдим ителә торган кыскача мәгълүмат;

инвестицион проектны алып бару – инвестицион проектны гамәлгә ашыруга административ ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән чаралар комплексы;

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының эшмәкәрлек һәм инвестицион климатны яхшырту буенча советы (алга таба – Совет) – «Тукай муниципаль районы Башлыгы каршында инвестицион совет төзү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгының 2023 елның 9 ноябрендәге

122 номерлы карары белән расланган даими эшләүче киңәшмә органы.

## II. Инвестицион проектны карау тәртибе

2.1. Инвестицион проект инициаторы Башкарма комитетка инвестицион проектны гамәлгә ашыру нияте турында (яки) инвестицион эшчәнлеккә ярдәм итү чараларын күрсәтү кирәклеге һәм (яки) дәүләт-хосусый партнерлык механизмнарын куллану (яисә) турында әлеге Регламентка 1 кушымта нигезендә форма буенча мөрәҗәгать җибәрә (алга таба – мөрәҗәгать).

Инвестицион проект инициаторы инвестицион проект буенча өстәмә мәгълүмат бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать кәгазьдә шәхсән яисә электрон рәвештә электрон почта аша: tukay.econom@mail.ru яки почта элемтәсе аша бирелә: 423800, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил ис. проспект, 46 йорт.

Алып баруга кабул ителә торган инвестицион проектлар инициаторлары түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

ликвидация процессында булмау;

аларга карата банкротлык процедурасы үткәрелмәү;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнарын бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар буенча срогы чыккан бурыч булмау;

хезмәт хакы түләү буенча бурычлар булмау;

аларның эшчәнлеге Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә туктатылган булырга тиеш түгел.

2.2. Мөрәҗәгать түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

инвестицион проектның бизнес-планы;

инвестор оешмасының тулы исеме, гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазифасы, почта адресы, элемтә телефоны, электрон почта адресы;

инвестицион проектның презентациые (булган очракта);

инвестицион проектның резюмесы;

инвестицион проектны гамәлгә ашыру өчен җитештерү мәйданчыгының яки җир кишәрлегенең кирәкле параметрлары турында әлеге Регламентка 2 кушымта нигезендә форма буенча мәгълүмат;

инвестицион проектны тормышка ашыру өчен шартлар һәм кирәкле таләпләр;

экологик күрсәткечләрне бәяләү.

Инвестицион проект инициаторы тарафыннан бизнес-планда тәкъдим ителгән барлык башлангыч мәгълүматлар һәм исәпләнгән зурлыклар өчен аларны алу чыганаклары күрсәтелә. Бәя зурлыклары өчен исәпләүләр китерелгән конкрет дата күрсәтелә.

Әгәр инвестицион проект инициаторы аны гамәлгә ашыруда конкрет оешмаларның, фондларның, үсеш институтларының катнашуын күздә тоткан очракта, тәкъдим ителгән материаллар әлеге оешмалар, фондлар, үсеш институтлары тарафыннан проектларга куелган таләпләргә туры килергә тиеш.

2.3. Тукай муниципаль районы территориясендә коммерция концессиясе шартнамәсе буенча үзләренә аерым хокукларны бирү белән кызыксынган инвестиция

проектлары инициаторлары тарафыннан мөрәҗәгатьләр кергәндә, түбәндәге документлар пакеты формалаштырыла:

оешма һәм аның эшчәнлеге турында мәгълүмат;

теркәлгән сәүдә маркасы, сертификатлар, булган чикләүләр турында мәгълүмат;

производствоны урнаштыру географиясе һәм концессия килешүләре шартлары;

эш нәтиҗәләре буенча финанс күрсәткечләренең кыскача тасвирламасы белән Россиянең башка төбәкләрендә, чит илләрдә шартнамәләрне гамәлгә ашыруның уңышлы мисаллары.

2.4. Инвестицион проект инициаторыннан әлеге Регламентның 2.3 пунктында каралган документларны теркәгән көннән алып 15 эш көне эчендә Башкарма комитет:

2.5.1. тәкъдим ителгән документларны анализлый һәм кирәк булганда инвестицион проект инициаторыннан өстәмә мәгълүмат сорый;

2.5.2. инвестицион проект инициаторына инвестицион проектны гамәлгә ашыруда ярдәм итү процедураларын «бер тәрәзә» принцибы буенча гамәлгә ашыру турында яисә әлеге процедураларны гамәлгә ашырудан баш тарту турында хәбәр итә;

2.5.3. инвестицион проект инициаторына ул дәгъва итәргә мөмкин булган дәүләт ярдәме инструментлары, шулай ук аларны куллану тәртибе турында хәбәр итә;

2.5.4. инвестицион проектларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру барышында әзерлек, килештерү һәм рөхсәт процедураларын үткәрү өчен, Башкарма комитетның структур бүлекчәләренә һәм бизнес-процессларга мөнәсәбәте булган башка оешмаларга мөрәҗәгатьләр җибәрә;

2.5.5. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы нигезендә инвестиция мәйданчыкларын алып бару өчен җаваплы структур бүлекчәгә инвестиция мәйданчыгын сайлап алуга гариза җибәрә.

Структур бүлекчә 15 эш көне дәвамында гаризаны карый һәм кирәк булганда инвесторга инвестиция мәйданчыгына кирәкле өстәмә таләпләр турында запрос җибәрә. Инвестор инвестиция мәйданчыгы турында өстәмә мәгълүмат биргәннән соң, инвестор таләпләренә җавап бирүче инвестиция мәйданчыкларын сайлауны башкара;

2.5.6. кирәкле инвестиция мәйданчыгын сайлап алу буенча мәгълүмат алгач, инвестицион проект инициаторына инвестиционя проектны гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча җавап әзерли һәм эш очрашуы, инвестиция мәйданчыкларын карау өчен дата билгели.

2.5. Җавап алгач, очрашулар үткәрелгәннән соң, инициатор Башкарма комитетка Тукай муниципаль районы территориясендә инвестицион проектны гамәлгә ашыру буенча үз карарын җиткерә.

Инвестор ризалык биргән очракта, Башкарма комитет инвестицион проектны Совет каравына чыгара. Совет тарафыннан карау нәтиҗәләре буенча инвестицион проектны алып баруның максатка ярашлылыгы яки максатка ярашсызлыгы турында карар чыгарыла.

2.6. Совет тарафыннан аны Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы һәм инвестицион проект инициаторына ярдәм күрсәтү кирәклеге турында инвестицион проект каралганнан соң өч эш көне

эчендә Башкарма комитет үз хезмәткәрләре составыннан инвестицион проект кураторын билгели.

2.7. Инвестицион проект кураторы инвестицион проектны гамәлгә ашыруда үз компетенциясе чикләрендә ярдәм күрсәтә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны мониторинглый.

2.8. Куратор инвестицион проект инициаторы белән берлектә проектны гамәлгә ашыру срокларын күрсәтеп, административ процедуралар проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле исемлекне үз эченә алган план-графикны әлеге Регламентның 4 кушымтасы нигезендә эшли һәм раслый.

2.9. Бүлек инвестицион проектны гамәлгә ашыруның бөтен срогы дәвамында кирәкле процедураларны план-график нигезендә гамәлгә ашыра.

2.10. Инвестицион проектны гамәлгә ашыру тәмамлангач, Башкарма комитет Советка аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат җибәрә.

2.11. Инвестицион проектны гамәлгә ашыруга «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү процедураларын башкарудан баш тарту өчен нигез булып әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән документларның берсе булмау, шулай ук инвестиция проекты турында тулы булмаган мәгълүмат бирү тора.

Баш тарткан очракта, Башкарма комитет документлар кергән көннән алып унбиш эш көне эчендә инициаторга мөрәҗәгатьне аңа теркәлгән документлар белән кире кайтара.

2.12. Мөрәҗәгатьне кире кайтару өчен нигез булган шартлар бетерелгән очракта, инициатор әлеге Регламент нигезендә Башкарма комитетка кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## III. Инвестицион проектларны алып бару

3.1. Тукай муниципаль районы территориясендә инвестицион проектларны алып бару түбәндәге формаларда башкарыла:

мәгълүмати, консультацион ярдәм күрсәтү;

Тукай муниципаль районы территориясендә инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен булган инвестицион мәйданчыклар буенча сайлап алу;

Тукай муниципаль районының инвестицион мөмкинлекләре һәм инвестицион потенциалы турында мәгълүмат бирү;

дәүләт, төбәк һәм муниципаль ярдәм чараларын күрсәтүне оештыру яки дәүләти-хосусый партнерлык механизмын куллану буенча тәкъдимнәр әзерләү;

инвестицион проектны гамәлгә ашыру процессында барлыкка килгән мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән сөйләшүләрне, очрашуларны, киңәшмәләрне, консультацияләрне оператив оештыру;

инвестицион проект инициаторы тарафыннан Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы законнары белән билгеләнгән, инвестицион проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле процедураларны, килештерүләрне, рөхсәтләрне үтәүдә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыру буенча координацияләү;

инвестицион проектны гамәлгә ашыру өчен өстәмә финанслау, финанс булмаган партнерлар (тәэмин итү, яңа технологияләр кертү, продукцияне алга җибәрү

һ.б. буенча) эзләүдә ярдәм күрсәтү;

Башкарма комитетның инвестицион эшчәнлегенә кагылышлы башка мәсьәләләрне карау.

## IV. Инвестицион проектлар реестрын алып бару

4.1. Башкарма комитет алып бара торган инвестицион проектлар әлеге Регламентка 3 кушымта нигезендә форма буенча Реестрга кертелә.

4.2. Реестрны Башкарма комитет алып бара.

4.3. Башкарма комитет инвестицион проект инициаторы белән берлектә ярты елга кимендә 1 тапкыр Реестрга кертелгән инвестицион проектны гамәлгә ашыруга мониторинг үткәрә.

Әгәр мониторинг үткәргәндә, Реестрга кертелгән инвестицион проект инициаторы тарафыннан календарь ел дәвамында эшчәнлек булмавы ачыкланса, инвестицион проект Реестрдан чыгарыла, инвестицион проектны алып бару туктатыла, инвестицион проект инициаторына, мондый хәлләр билгеләнгән көннән алып 7 эш көненнән дә соңга калмыйча, бу хакта язма рәвештә хәбәр ителә.

4.4. Реестр инвестицион проектларн алып баруга кабул ителгән яки инвестиция проектлары реестрыннан әлеге Регламентның 4.3 пунктында күрсәтелгән очракта чыгарылган саен яңартыла.

4.5. Реестрга кертелгән инвестицион проектларны гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүмат Башкарма комитет тарафыннан районның рәсми сайтында урнаштырыла https://tukay.tatarstan.ru/.

## V. Өстенлекле инвестицион проект

Өстенлекле инвестицион проект Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган яки гамәлгә ашыру планлаштырылган инвестицион проектларны Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

Инвестицион проектларны сайлап алганда һәм өстенлекле инвестиция проектын билгеләгәндә, шул исәптән исәпкә алына:

а) кертү күздә тотылган инвестицияләр күләме;

б) Тукай муниципаль районы бюджетының күздә тотылган салым керемнәре күләме;

в) инвестицион проектның яңа эш урыннары булдыру, яңа технологияләр кертү, яңа товарлар һәм хезмәтләр булдыру, шулай ук гамәлдәге производстволарны үзгәртеп кору һәм модернизацияләү буенча бурычларны хәл итүгә юнәлтелгән булуы.

Татарстан Республикасы законнары нигезендә махсус инвестицион контракт төзелгән инвестицион проектка Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан расланган тәртиптә «өстенлекле инвестицион проект» статусы бирелә. Инвестицион проектны сайлап алу, өстенлекле инвестиция проекты статусын бирү нәтиҗәләре буенча инвестор белән инвестиция килешүе төзелә.

Инвестор инвестицион килешү төзүдән баш тартса, өстенлекле инвестицион проект статусы туктатыла, инвесторга дәүләт ярдәме чаралары бирелми.

## VI. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Башкарма комитетка бирелгән мәгълүматларның дөреслеге өчен инвестор һәм (яки) инвестицион проект инициаторы җаваплылыкка ия.

6.2. Идарә инвестицион проектларны алып баруны, инвесторлар һәм (яки) инвестицион проектлар инициаторлары белән үзара хезмәттәшлек этаплары турында мәгълүматны теркәүне гамәлгә ашыра.